КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 23 декабрь г.Казань № 1273

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елда яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) белән авыручы, амбулатор шартларда медицина ярдәме күрсәтелүче пациентларны дәвалау өчен дарулар сатып алу чараларын финанслар белән тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган максатчан билгеләнешкә ия башка бюджетара трансферттан файдалану тәртибен раслау турында» 2021 ел, 10 апрель, 233 нче карары белән расланган 2021 елда яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) белән авыручы, амбулатор шартларда медицина ярдәме күрсәтелүче пациентларны дәвалау өчен дарулар сатып алу чараларын финанслар белән тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган максатчан билгеләнешкә ия башка бюджетара трансферттан файдалану тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елда яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) белән авыручы, амбулатор шартларда медицина ярдәме күрсәтелүче пациентларны дәвалау өчен дарулар сатып алу чараларын финанслар белән тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен

финанслашу максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган максатчан билгеләнешкә ия башка бюджетара трансферттан файдалану тәртибен раслау турында» 2021 ел, 10 апрель, 233 нче карары белән расланган 2021 елда яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) белән авыручы, амбулатор шартларда медицина ярдәме күрсәтелүче пациентларны дәвалау өчен дарулар сатып алу чараларын финанслар белән тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган максатчан билгеләнешкә ия башка бюджетара трансферттан файдалану тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта:

«(алга таба – яңа коронавирус йогышлы авыруы белән авыручы пациентлар)» сүзләрен «(алга таба – шул ук эзлеклелектә яңа коронавирус йогышлы авыруы белән авыручы пациентлар, вакытлыча методик тәкъдимнамәләр)» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«2021 елның 1 октябренә сатып алынган һәм, вакытлыча методик тәкъдимнамәләрдә амбулатор шартларда дәвалау өчен билгеләнгән, тәкъдим ителгән схемалардан даруларны төшереп калдыруга бәйле рәвештә, башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәләренә, шул исәптән Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма буенча төзелгән Башка бюджетара трансфертлар бирү турындагы килешүдә (алга таба – Килешү) каралган вакытлыча методик тәкъдимнамәләр нигезендә башка дару препаратларын файдаланып ирешелгән очракта, барлыкка килгән даруларның калган өлеше яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) белән авыручы, стационар шартларда вакытлыча методик тәкъдимнамәләр нигезендә медицина ярдәме күрсәтелүче пациентларны дәвалау өчен, шулай ук башка медицина максатларында кулланыла.»;

7 пунктның беренче абзацында «Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында башка бюджетара трансферт бирү турындагы килешүдә» сүзләрен «Килешүдә» сүзенә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин